КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2021 ел, 25 ноябрь г.Казань № 1118

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Өлешле төзелештә катнашучы гражданнарның хокукларын яклау фонды» гавами-хокукый компаниясенә Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия бирү тәртибен раслау турында» 2019 ел, 25 октябрь, 959 нчы карары белән расланган «Өлешле төзелештә катнашучы гражданнарның хокукларын яклау фонды» гавами-хокукый компаниясенә Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия бирү тәртибенә үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Өлешле төзелештә катнашучы гражданнарның хокукларын яклау фонды» гавами-хокукый компаниясенә Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия бирү тәртибен раслау турында» 2019 ел, 25 октябрь, 959 нчы карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2020 ел, 10 ноябрь, 1005 нче; 2020 ел, 24 ноябрь, 1057 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган «Өлешле төзелештә катнашучы гражданнарның хокукларын яклау фонды» гавами-хокукый компаниясенә Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия бирү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

4 пунктны түбәндәге редакциядә бирергә:

«4. Субсидия Фондның Субсидия бирү турындагы килешү (алга таба – Килешү) төзелгән айга кадәрге айның 1 енә түбәндәге таләпләргә туры килүе шарты белән бирелә:

салымнар һәм җыемнар турындагы Россия Федерациясе законнары нигезендә түләнергә тиешле салымнар, җыемнар, иминият кертемнәре, пенялар, штрафлар, процентлар түләү буенча үтәлмәгән йөкләмәсе булмау;

үзгәртеп оештыру, бетерү процессында булмау, аңа карата банкротлык процедурасы билгеләнмәү, Фонд эшчәнлеге Россия Федерациясе законнары белән күздә тотылган тәртиптә туктатылмау;

субсидияләрне, бюджет инвестицияләрен, шул исәптән башка хокукый актлар нигезендә бирелгәннәрне Татарстан Республикасы бюджетына кире кайтару буенча үз вакытында түләнмәгән (җайга салынмаган) бурычлары һәм Татарстан Республикасы бюджеты алдында акча йөкләмәләре буенча үз вакытында түләнмәгән башка бурычлары булмау;

дисквалификацияләнгән затлар реестрында дисквалификацияләнгән Фонд җитәкчесе, Фондның коллегиаль башкарма органы әгъзалары, Фондның бер кеше башкара торган башкарма органы функциясен үтәүче зат яки Фондның баш бухгалтеры турында мәгълүматлар булмау;

чит ил юридик заты, шулай ук Россия Федерациясе Финанс министрлыгы раслый торган, салым салуның ташламалы салым режимы бирелә торган һәм (яки) мондый юридик затларга карата финанс операцияләрен уздырганда мәгълүмат ачуны һәм бирүне күздә тотмаган дәүләтләр һәм территорияләр (офшор зоналары) исемлегенә кертелгән дәүләт яки территория теркәлү урыны булып торган, устав (җыелма) капиталында чит илләр юридик затларының катнашу өлеше барысы бергә җыеп исәпләгәндә 50 проценттан артмаган Россия юридик заты булып тормау;

Татарстан Республикасының башка норматив хокукый актлары нигезендә бу Тәртип белән билгеләнгән максатлар өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан акча алмау.»;

түбәндәге эчтәлекле 4.1 пункт өстәргә:

«4.1. Субсидия бирү шартлары түбәндәгеләр була:

«Фонд тарафыннан Субсидия күчерү датасына Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Өлешле төзелештә катнашучы гражданнарның хокукларын яклау фонды» гавами-хокукый компаниясе тарафыннан «Төзүчеләр бөлгенлеккә (банкротлыкка) төшкәндә Өлешле төзелештә катнашучы гражданнарның хокукларын яклау буенча гавами-хокукый компания турында һәм Россия Федерациясенең аерым актлары үз көчен югалткан дип тану хакында» Федераль законның 13.1 статьясындагы 2 өлеше белән каралган чараларны финанслау турында яки чараларны финанслау максатка туры килмәү турында карар кабул итү кагыйдәләрен раслау хакында һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актлары үз көчен югалткан дип тану турында» 2019 елның 12 сентябрендәге 1192 номерлы карары белән расланган Өлешле төзелештә катнашучы гражданнарның хокукларын яклау фонды» гавами-хокукый компаниясе тарафыннан «Төзүчеләр бөлгенлеккә (банкротлыкка) төшкәндә Өлешле төзелештә катнашучы гражданнарның хокукларын яклау буенча гавами-хокукый компания турында һәм Россия Федерациясенең аерым актлары үз көчен югалткан дип тану хакында» Федераль законның 13.1 статьясындагы 2 өлеше белән каралган чараларны финанслау турында яки чараларны финанслау максатка туры килмәү турында карар кабул итү кагыйдәләре (алга таба – Карар кабул итү кагыйдәләре) нигезендә финанслар бирү турында карар кабул итү;

Министрлык һәм дәүләт финанс контроле органнары тарафыннан Фондның субсидия бирү шартларын, максатларын һәм тәртибен үтәвенә тикшерүләрне гамәлгә ашыруга аның ризалыгы;

5 пунктның өченче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Фонд җитәкчесе яки башка вәкаләтле зат тарафыннан имзаланган, Фондның бу Тәртипнең 4 пунктында күрсәтелгән таләпләргә туры килүе турындагы мәгълүматны үз эченә алган хат;»;

6 пунктның икенче абзацында «күчермәсен» сүзеннән соң «яисә Юридик затларның бердәм дәүләт реестрыннан язу кәгазе күчермәсен» сүзләрен өстәргә;

10 пунктның өченче һәм дүртенче абзацларын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Фонд тарафыннан тапшырылган документларның бу Тәртипнең 5 пунктында каралган таләпләргә туры килмәве;

Фонд тарафыннан бирелгән мәгълүматның дөрес булмавы фактын билгеләү.»;

11 – 13 пунктларны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«11. Субсидия күләме тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турындагы Татарстан Республикасы законы белән билгеләнә.

12. Субсидия бирү Министрлык һәм Фонд арасында төзелә торган Килешү нигезендә, Карар кабул итү кагыйдәләренә 2 нче кушымтада билгеләнгән килешүнең бертип формасы буенча гамәлгә ашырыла.

Килешүдә шул исәптән түбәндәгеләр карала:

бу Тәртипнең 3 пунктында күрсәтелгән, Министрлыкка элек җиткерелгән бюджет йөкләмәләре лимитларын Килешүдә билгеләнгән күләмдә Субсидия бирү мөмкинлеге булмауга китерә торган итеп киметкән очракта, Фонд белән Килешүнең яңа шартларын килештерү турында шарт;

Фонд тарафыннан Субсидия исәбеннән чит ил валютасын (югары технологияле импорт җиһазы, чимал һәм комплектлау әйберләре сатып алганда (кайтартканда) Россия Федерациясе валютасы законнары нигезендә гамәлгә ашырыла торган, шулай ук әлеге акчаны бирү максатына ирешүгә бәйле булган, дәүләт (муниципаль) учреждениеләре булмаган, коммерциягә карамаган оешмаларга субсидияләр бирү тәртибен җайга сала торган норматив хокукый актлар белән билгеләнгән башка операцияләрдән тыш) сатып алуга тыю.

13. Субсидия бирү нәтиҗәсе – «Төзүчеләр бөлгенлеккә (банкротлыкка) төшкәндә өлешле төзелештә катнашучы гражданнарның хокукларын яклау буенча гавами - хокукый компания турында һәм Россия Федерациясенең кайбер закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2017 елның 29 июлендәге 218-ФЗ номерлы Федераль законның 13 статьясы нигезендә торак урыннарны тапшыру буенча йөкләмәләр үтәлгән яисә акча түләнгән гражданнар саны.

Субсидия бирү нәтиҗәсенең мәгънәсе һәм аңа ирешү срогы Килешүдә билгеләнә, аның бертип формасы Карар кабул итү кагыйдәләренә 2 нче кушымтада бирелә.»;

15 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«15. Фонд, Субсидия бирү нәтиҗәсенең мәгънәсенә ирешү срогы башланганнан соң 10 эш көненнән дә соңга калмыйча, Килешүдә билгеләнгән һәм бертип формасы

Карар кабул итү кагыйдәләренең 2 нче кушымтасында бирелгән форма буенча Фондның бу Тәртипнең 13 пунктында күрсәтелгән Субсидия бирү нәтиҗәсенең мәгънәсенә ирешүе турындагы хисапны Министрлыкка кертә.»;

16 пунктта «үтәлешен» сүзеннән соң «мәҗбүри» сүзен өстәргә;

17 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«17. Тикшерүләр йомгаклары буенча Фонд тарафыннан бу Тәртиптә билгеләнгән Субсидия бирү максатларын, шартларын һәм тәртибен бозулар факты ачыкланган, шулай ук Фонд тарафыннан бу Тәртип һәм Килешү нигезендә тапшырылган документларда дөрес булмаган мәгълүматлар күрсәтелгән очракта, Субсидия яки аның өлешләре кире кайтарылырга тиеш.»;

түбәндәге эчтәлекле 20 пункт өстәргә:

«20. Субсидияне максатчан файдалануны контрольдә тоту Министрлык тарафыннан Россия Федерациясе законнары нигезендә гамәлгә ашырыла.».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин